Балык бистәсе районы Олы Елга урта гомуми белем бирү мәктәбе

# Яңа көн

Март 2019

*Исәнмесез, кадерле дуслар! Урамда яз җилләре исә. Яз битләребезгә дә, хисләребезгә дә үзенең җылысын өрә. Яз үзенең сихри көчләре белән кешеләр күңеленә үк үтеп керә: җан, рухка ниндидер көтелмәгән куаныч иңәр төсле, бәхет-шатлыкка юл ачылыр сыман.. Язлар матур, дибез. Бәлки яз хатын-кызлар бәйрәме белән матурдыр?*

*Хөрмәтле гүзәл затларыбыз! Сезне яз бәйрәме белән котлыйбыз!*



## Бу санда:


- 23 февраль - Ватанны саклаучылар көне
- Туган тел бәйрәме
- Яңалыклар


**Гүзәл затлар, сезгә дип багышлап,**
**Күпме җырлар иҗат ителә**
**Ай-кояшка, йолдызларга тиңләп,**
**Моң агыла йөрәк түреннән.**

**Тормыш бүләк иткән аналарның**
**Җан җылысын тоеп туймаслык,**
**Сабырлыгы, изгелеге өчен,**
**Һәрберсенә һәйкәл куярлык.**





23 февраль — Ватанны саклаучылар коне – батырлык, намус һәм кыюлык көне белән ихластан котлыйбыз сезне. Бүгенге бәйрәм көчле рухлылык, ир-егетләрнең кыюлык, намус һәм абруй шикелле сыйфатларга ия булуларын тагын бер кат раслый торган тантана. Туган илгә һәм үз халкыңа хезмәт итү ул, туган илен чын күңелдән сөюче гражданнарның һәрчак иң югары максаты булды һәм шулай ук булып калса иде.

Хәрби хезмәткәрләрнең бүгенге көндәге буыны һәм Ватанны саклаучылар сафын тулыландырырга әзерләнүчеләр, илебезнең иминлеге, туганнары һәм якыннарының гомере өчен җаваплылык хисен онытмасыннар иде.

Сезгә һәм якыннарыгызга тыныч күк йөзе, ныклы сәламәтлек, бәхет-шатлык, рухи һәм матди байлык, һәр эшегездә бары тик уңышлар гына телибез. Мөбәрак булсын бүгенге матур бәйрәмегез!!!



13 нче февраль көнне мәктәбебездә хәрби-патриотик айлык кысаларында “Ажаган - 2019” уены булып үтте. Уенда дүрт хәрби төркем катнашты. Уен программасында хәрби-тарихи викторина , тормыш куркынычсызлыгы нигезләре буенча сораулар, хәрби-патриотик җырлар бәйгеләре, физик күнегүләр, Калашников автоматын сүтү-җыю, пневматик винтовкадан ату, хәрби темага мәкальләр һәм әйтемнәр белүдә, миналарны “зарарсызландырдылар”, гранаталар “аттылар”, разведкага йөрделәр, “яралыларга” ярдәм күрсәттеләр.




Укучылар үзләрен көчле, батыр, җитез итеп кенә түгел, ә тату, бердәм команда булуларын да күрсәттеләр. Хәрби-спорт уенында актив катнашкан отрядлар Мактау грамоталары белән бүләкләнде. Кыюлыкта, чыдамлыкта сыналырга ярдәм иткән хәрби уен бик күңелле узды.




***21 нче февраль - Һәр милләт, һәр халык өчен бәйрәм көн - Халыкара туган тел көне. Һәркем өчен дөньядагы барлык телләр арасында иң кадерлесе - тәүге кабат сөйләшә башлаган ана теле. Бу - безнең балачагыбыз, гаиләбез, җәмгыятьтәге беренче тапкыр аралашуыбыз теле. Халыкара туган тел көнендә барлык телләр дә, тигез дип таныла, чөнки аларның һәркайсы кеше язмышы өчен җавап бирә һәм без аны сакларга тиешбез. Әлеге истәлекле көнгә багышлап, мәктәбебездә "Иң матур тел - туган тел, иң матур көй - милли көй!" дигән әдәби - музыкаль кичә уздырылды. Татар теле укытучысы - Мөбәрәкшина Әлфинур Әдип кызы тарафыннан үткәрелгән бәйрәм бик кызыклы, файдалы, укучылар күңеленә үтеп кererлек итеп уздырылды. Кичәдә туган телгә багышланган шигырьләр, мәкальләр, җырлар тыңланды, бәйрәм ахырында Г.Тукай сүзләренә язылган “Туган тел” җыры гимн булып яңгырады. Бәйрәм бик күңелле булды!***



**Районыбызда “Иң шәп вожатый - 2019” бәйгесе булды. Анда мәктәбебезнең 8 нче сыйныф укучысы Сибгатуллина Г. катнашты. Ул бәйгенең барлык этапларында да яхшы гына чыгыш ясап, югары баллар җыйды. Һәм бәйгенең “Иң ягымлы әйдаманы» исеменә лаек булды. Гөлсәриягә алга таба да уңышлар теләп калабыз. Син булдырасың, әфәрин!**






27 февраль көнне 5-8 сыйныф укучылары арасында рус теле укытучысы Сафиуллина С.Г. житәкчелегендә «Тере классика» - Бөтенроссия конкурсының мәктәп этабы узды. 1 урынны 6 сыйныф укучысы Альмиев Р., 2 урынны 5 һәм 6 сыйныф укучылары Галиева Я., Хасанова Я. яулады. Барлык катнашучылар Рәхмәт хатлары белән бүләкләнделәр.

***23 февраль көнне Олы Елга авылы мәдәният йортында Ватанны саклаучылар көненә багышланган “Туган якка солдат сәламе” дигән әдәби музыкаль кичә узды. Бәйрәмне 11 сыйныф укучылары Гильмутдинов.И.Р. һәм Салахова А.Ф. җитәкчелегендә оештырдылар. Кичә котлаулар һәм җыр-биюләр белән үрелеп барылды. Бәйрәм бик күңелле узды, матур хатирәләр булып күңелләрдә калды.***




***Редколлегия: Олы Елга урта мәктәбенең 7 нче сыйныф укучылары***